ГЛАВА КАРАКАШЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Сирина Батыршина,,д.33,
с.Каракашлы 423961

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Сирин Батыршин урамы, 33 йорт,
Кәрәкәшле авылы, 423961

Тел.:(85593) 4-21-21, факс:4-21-21, e-mail: Karak.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» октябрь 2024 ел № 19

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 25 октябрендәге 15 номерлы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче Ак-Чишмә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 26 маддәсе нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгының «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге составына керүче Ак Чишмә торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында» 2024 елның 25 октябрендәге 15 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең Ак-Чишмә торак пункты территориясендә 2025 елда яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның якын туганнарыннан (ата-аналарыннан,тормыш иптәшләреннән), Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылганнар гражданнардан тыш, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне

башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә сез ризамы?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Ак Чишмә торак пунктында юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту (эшләр һәм шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү (каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыгын урнаштыру) (Ак Чишмә торак пунктында контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү))».

«РИЗА» «КАРШЫ»

1.2. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башкарма комитетына Ак-Чишмә торак пунктында гражданнар җыенын оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (http://jutaza.tatarstan.ru.), http://pravo.tatarstan.ru / электрон адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында кабул ителгән көннән алып 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев